ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 өлештә “2.1 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне (телләр турында Татарстан Республикасы законнарын гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга яисә гражданнарның мәгариф өлкәсендә телгә караган хокукларын чикләүгә китергән бозуларга кагылышлы)” сүзләрен “2.1, 3.11 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне (телләр турында Татарстан Республикасы законнарын гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга яисә гражданнарның мәгариф өлкәсендә телгә караган хокукларын чикләүгә китергән бозуларга кагылышлы)” сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 өлештә “2.11 статьясында” сүзләрен “ 2.11, 3.8 статьяларында” сүзләренә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ һәм $11^2$ өлешләр өстәргә:

“$11^1$. Әлеге Кодекснең 3.14 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының вазыйфаи затлары төзи.

$11^2$. Әлеге Кодекснең 3.15 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының вазыйфаи затлары төзи.”;

5) $13^1$ өлештә “2, 5, 9 өлешләрендә” сүзләрен “5, 9 өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

6) 14 өлештә “1, 2, 4, 5, 9, $13^1$ өлешләрендә” сүзләрен “1, 3 – 5, 7, 9, $11^1$, $11^2$, $13^1$ өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле 17 өлеш өстәргә:

“17. Вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру турында федераль башкарма хакимиятнең эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында килешү төзелгән очракта, әлеге Кодексның 3.8, 3.11, 3.14, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне эчке эшләр органнарының (полициянең) вазыйфаи затлары төзи.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 9 июле
№60-ТРЗ